**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ГЛАВА АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан,Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**1 ноябрь 2022 ел** **№ 9**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Зур Көек торак пунктында гражданнарның 2021 елда җыелган үзара салым акчаларының калган өлешен тоту буенча гражданнар җыены билгеләү турында

."Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, 25.1 ст.нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, ст. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең 22 Уставы һәм 2019 елның 23 октябрендәге 162 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Зур Көек торак пунктында гражданнарның 2021 елда җыелган үзара салым акчаларының калган өлешен тоту турында гражданнар җыенын 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Зур Көек авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт адресы буенча (китапханә янында) билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек авылы территориясендә гражданнарның 2021 елда җыелган үзара салым акчаларының калган өлешен түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга ризамы?”:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (ТР Биектау районының Зур Көек торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу җайланмасы булдыру мөмкинлеге турында килешү буенча түләү, шулай ук скважина бораулау проектын эшләүгә түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин